КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 февраль г.Казань 113

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы генераль директорын конкурс нигезендә билгеләп кую тәртибен раслау турында» 2014 ел, 13 декабрь, 984 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы генераль директорын конкурс нигезендә билгеләп кую тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы генераль директорын конкурс нигезендә билгеләп кую тәртибен раслау турында» 2014 ел, 13 декабрь, 984 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 14 сентябрь, 642 нче, 2019 ел, 18 октябрь, 934 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы генераль директорын конкурс нигезендә билгеләп кую тәртибенә, 3.3 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«тиешенчә расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин